СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 г. №120

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советының «Милеккә салым турында»гы 29.06.2022 №50 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Советының «Мөлкәткә салым турында» 2022елның 29 июнендәге 50 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.4. пунктта «, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга,шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Югары Субаш авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы А.А.Хөснетдинов